Г.Тукай ис. Мөслим  урта гомуми белем бирү мәктәбе



# Тукай ялкыны

ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

“ Туган телне сөючеләр” пресс-центры **Ноябрь, 2023 нче ел** №2

ФОАТ САДРИЕВ

БОЗ ӨСТЕНДӘ (Хикәя.)

Көзге каникулдан соң көннәр бик суытты, елгалар, күлләр боз белән капланды, бала-чага тимераякта шуа башлады.

Илнур белән Кәрим дә боз өстеннән кайтып кермәделәр. Дөрес, аларга әти-әниләре инештә генә шуарга рөхсәт итте.

Бүген алар мәктәптән бик иртә кайтты. Бозда әле беркем юк. Аяклар белән як-якка этенеп йөгерәсең дә шуып китәсең. Колак төбендә җил сызгыра, суык бабай битләрне чеметтереп ала, ә сиңа болар әллә бар, әллә юк. Кызу-кызу йөгергәч, битләр ут булып яна, суыкны сизмисең дә. Малайлар тирләп пеште, бүрек колакчыннарына хәтле күтәреп бәйләделәр, хәтта бияләйләрен дә салдылар.

Малайлар инешнең Ыкка кушылган җиренә таба шуды. Инеш ярлары һаман биегәя барды. Ахырда алар Ыкка килеп җитте. Монда боз шоп-шома иде. Илнур бозга тезләнде дә:

— Кил, аквариум күрсәтәм! — диде.

Кәрим, кызык күрергә әзерләнеп, аның янына шуып килде.

— Карале, кара!

Алар, икәүләшеп, суга төбәлде. Менә тамаша кайда икән ул! Су төбендәге эреле-ваклы ташлар һәммәсе аермачык күренә. Әнә бармактан әз генә зуррак балыклар йөзеп йөри. Аларның сыртлары тал яфрагы төсле озынча һәм яшькелт төстә. Балыклар ашыкмый, акрын гына агымга каршы йөзәләр.

— Монда бик сай,— диде Илнур.— Әйдә, тирәнрәк җирдән эре балыклар карыйбыз.

Кәримнең эре балыкларны бик тә күрәсе килде. Менә әти-әниләренең кисәтүе генә...

— Ыкка керергә ярамый бит,— диде ул, аларның сүзен исенә төшереп.

— Бер генә мәртәбә карыйбыз да кире борылабыз!

Шулай дип, Илнур алга ыргылды. Ай-яй кызу шуып китте! Артыннан боз сыгылып ук калды.

Кәрим дә бер генә мәртәбә шуып карарга булды. Этенеп кереп киткән иде, рәхәтлектән өнсез калды. Әллә тагын аны һавага күтәреп җибәрделәр?! Боз пластмасса кебек сыгыла, үзе чатнап та карамый, артыңнан кабат элекке хәленә кайтып кала. Гел дулкын өстендә йөргән төсле. Мондагы боз, инешнеке белән чагыштырганда, пыяла кебек иде. Әз генә этелсәң дә, әллә кая ук шуып китәсең.

— Күр, мин кая ук барып җиттем,— ди Илнур һәм зур ярымтүгәрәк ясап шуып китә.

— Ә хәзер мине кара! — дип, Кәрим дә үзенең аннан калышмавын күрсәтә.

Алар Ык бозына эре балык карарга дип кенә керүләрен онытып җибәрде. Менә Илнур, шуа-шуа, Ыкның уртасына таба ук элдерде.

Кәрим аңа кычкырмакчы булган иде, кинәт чатырдаган тавыш ишетелде, һәм, боз ватылып китеп, Илнур суга чумды.

Ул күкрәктән суда килеш бозга ябыша, ябышкан саен, боз ватыла иде.

— Чыга алмыйм! — дип кычкырды ул, елый-елый.

— Илнур, көт... мин хәзер!..

Кәрим яр буендагы таллыкка шуып китте. Сындырмакчы булып, әле бер, әле икенче талга ябышты, тик алар бөгелеп кенә торалар иде.

Эзли торгач, таза гына бер колга тапты. Шуны алып, Илнурга таба ашыкты. Ләкин барып җитә алмады, боз янә хәтәр чатырдап китте.

Аңа туктарга туры килде. Аннары ул, бозга ятып, Илнурга таба шуышты. Уйнаганда, карда батмас өчен, шулай итәләр иде алар. Гәүдәсе астында бозның сыгылуын ул бөтен тәне белән сизде. «Ватылмасын, түзсен генә»,— дип уйлады эченнән. Илнур баткан урыннан боз өстенә су җәелгән, бөтән якынлашырлык түгел иде. Кәрим каешын колгага бәйләде дә аны Илнур ягына селтәп җибәрде:

— Әйдә, ябыш!

Илнур, елаудан туктап, каешка үрелде, тик кулы җитмәде. Ул тагын да ныграк еларга тотынды.

Нишләргә? Шунда Кәримнең башына бер уй килде. Ул тиз генә чишенә башлады. Майкадан гына калгач, суык аны өттереп-өттереп алды, бала йоннары кабарып чыкты, үзе дер-дер калтыранды. Кәрим ашыга-кабалана пәлтәсен киде. Аннары күшегеп беткән куллары белән свитер җиңен күлмәк җиңенә бәйләде, тезенә кысып тартты, чишелмәслек итте. Күлмәкнең икенче җиңен каешка бәйләде. Шуннан соң колганы, югары күтәрмичә генә, ян-яктан Илнурга селтәде.

— Күлмәк җиңеннән эләктер! — диде Кәрим, түшенә ятып.

Ул колганы ике кулы белән чытырдатып кысты. Илнур бу юлы күлмәкне эләктереп алды һәм боз өстенә менмәкче булып тартыла башлады.

Кинәт Кәрим үзенең боздан шууын сизде, һәм аның беләкләрен, тезләрен салкын су өтеп алды. Илнур тарткан саен, ул боз өстенә җәелгән су эченә сөйрәлеп керә иде.

Кәрим, яткан килеш, уң аягын күтәреп бозга бәрде. Тимераяк очы бозны тишеп керде, һәм ул колгага сөйрәлеп барудан туктады. Аякның йөзен туры гына тотарга кирәк. Кәрим сул тимераягының да очын нәкъ шул рәвешле бозга батырды. Тал колга бик нык тартылды, кулдан инде шуып чыга, инде шуып чыга дигәндә, Илнур акрын гына боз өстенә күтәрелә башлады. Кәрим ашыга-ашыга чигенде. Икесе бер урынга туры килсәләр, бозның тагын ватылу куркынычы бар иде...

Тулырак: http://chelny-rt.ru/news/ədəbi-səhi..

## Мәктәп яңалыклары...

Хөрмәтле әти-әниләр!Кышкы чорда су буйларында балаларны ялгыз калдырмагыз! Балаларга боз уеннары куркыныч күңел ачу икәнен аңлатырга кирәк. Кеше авырлыгы астында көзге боз ярылырга мөмкин. Балаларга бозга чыгу куркынычы турында сөйләргә, буш вакытын кайда үткәрүе белән кызыксынырга, балаларның көзге-кышкы чорда сулыкларда булуына юл куймаска кирәк. Боз өстендә уеннар рөхсәт ителми!Балаларның бу кагыйдәләрне белмәве - фаҗигагә беренче сәбәп.Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта, ашыгыч рәвештә 112 телефонына шалтыратырга кирәк (барлык шалтыратулар да бушлай).



"Без бергә" балалар фестивале республика туры җиңүчеләренең гала-концертында 1 урын алган Сөмбел Ибраһимова, Ринат Максутовны уңышлары белән котлыйбыз.Җитәкчеләре Энҗе Ибраһимова.



Оператив-профилактик чаралар кысаларында, шулай ук «Үзәк китапханә» дә психолог көне уңаеннан Сарман районы буенча "Юл хәрәкәте иминлеге" ДБУ бүлеге җитәкчесе Ситдыйкова Алсу Разиновна Мөслим районы педагог-психологлары өчен китапханә хезмәткәрләре белән берлектә «Могҗизалар кыры» интеллектуаль уенын оештырдылар. Шоу башында уен кагыйдәләре аңлатыла һәм өч уенчы билгеләнә. Һәр уен өчлегенең җиңүчеләре финалда очраштылар, «Могҗизалар кыры» капитал-шоу уенында Г.Тукай ис. Мөслим мәктәбенең педагог – психологы Хәлиуллина Ләйсән Максут кызы җиңүче булды. Шоу-уен атмосферасы бөтен кеше яраткан экран версиясе белән тулысынча туры килә, күңелле һәм иҗади була. Педагоглар биремнәр турында фикер алышу өчен рәхәтләнеп вакыт үткәрделәр һәм мөмкин кадәр күбрәк дөрес хәрефләрне

## Г.Тукай ис.Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбендә Ф.Садривның “Авылдан хатлар” әсәре буенча китап укучылар конференциясе

-Хәерле көн кадерле укучылар, хөрмәтле татар теле һәм әдәбияты укытучылары!
-Ф.Садриевның “Авылдан хатлар”әсәре буенча әзерләнгән китап укучылар конференциясен башлап җибәрергә рөхсәт итегез.
-Бүгенге конференциянең кунаклары: җирлегебезнед мөхтәрәм шәхесе, олуг язучыбыз Фоат абый Садриев, Мәгариф идарәсе методисты Нурания Әзгәм кызы, шулай ук татар теле һәм әдәбияты укытучылары.
Презентация 5 слайдтан торган.
-Кем соң ул Ф.Садриев? Язучы -прозаик, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе , Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай премиясе лауреаты. Фоат Садриевның кайсы гына әсәрен алма, гади, гадәти авыл тормышы, авыл кешеләре, гади сөйләшүләр, гади сөйләм теле. Без һәр әсәрне укыганда, сүзләрнең нәкъ без кулланып сөйләшә торган сүзләр икәнен күрдек, һәм безнең сөйләмне автор ничек шулкадәр белеп, оста итеп яза алуына сокландык.
- Әсәр язучының авылга мөрәҗәгате, ягъни беренче хаты белән башланып китә.Язучы үзе дә тамырдан авыл кешесе;шунда туып-үскән,яшәгән, ата-бабалары авылныкы.
(ятлаган укучылар сәнгатьле итеп сөйлиләр)
А.Б-Авылны автор уртак Анабыз дип атый.
А.Б-“Без авыл кешеләре” дигән юлларда горурлану хисләре яңгырый.Авыл ул-бер зур гаилә.
Беренче укучы авыл турында сөйли
Икенче укучы авыл тормышын, яшәешен дәвам итә.
А.Б.-Әйе, бу безнең үткәнебез, безнең тарихыбыз.Әби –бабайларыбызның михнәт, газап чигеп яшәүләре.Безнең матур, тыныч тормышыбызның үткәне
А.Б.Авылның күрке , аны туендыручы, киендерүче яшәргә өмет уятучы –басу.Басу хезмәт, басу –икмәк.Язучының басуны олылавы, аңа карата язылган юлларның тирәнлегенә сокланабыз.
Укучы басу турында юлларны укый.
А.Б. Борын-борыннан килгән бер риваятькә игътибар итик әле..Берәү ялгыш ипи валчыгын җиргә төшереп җибәрә.Һәм эзләп-эзләп тә таба алмый.Валчык тапталмасын дип ул урынны киртә белән әйләндереп ала. Менә бу инде икмәкнең дәрәҗәсе, ә икмәкне бирүче басу.
А.Б. Язучыбыз йөрәгендәге хисләрен иң кадерле кешесе Анасы белән бәйли. Ул безнең миллионлаган әниләребез. Хатларда аларның ныклыгы, авырлыкларга бирешмичә, сынмыйча яшәүләрен бәян итә.
Әни турында сөйләү.
А.Б.Кем баласы булуга карамастан ул апалар-әниләр барыбызга да җан җылыларын тигез өләшеп, үлемнән коткарып калдылар, эшкә, гаделлеккә , намуслы, шәфкатьле булырга, нинди генә авырлыклар килсә дә тормышның ямен күрергә өйрәттеләр, искиткеч матур телебезне, гореф –гадәтләребезне, җырыбызны моңыбызны биреп калдырдылар. Их сез әнкәйләр буыны.Мең-мең рәхмәт Сезгә.
А.Б.Мәхәббәт, ярату –иң бөек тойгы.Иң беренчесе әнигә карата, аннан әтигә.Сабыйның ярату тойгысы шулай үсә.Бала өй эчен ярату белән җанына сеңдерә.Озакламый туган йорт, ишегалды, агачлар, урам, һава, җир, хайваннарны җанына сеңдерә.Менә шулай акрынлап туган җирне, туган илне ярату барлыкка килә, үсә, чәчәк ата.
-хикәя, туган авылны сагынып кайту
А.Б.Язучы “Нишләргә соң инде синең белән туган нигез? дигән сорауны бик борчылып бирә.
Укучы туган нигез турында укый.
А.Б.Әйе, туган нигез сиңа яшәргә көч биргән, сагынып кайту үзәгенә әйләнгән урын бит ул. Ул шундый кадерле, якын.
А.Б. Авыл. Туган җир. Нигез. Авыл сабантуйлары.Берничек тә бер-берсеннән аерылмый торган төшенчәләр.
Укучы сабантуй турында сөйли.
А.Б.Бу буыннан буынга килгән гореф-гадәтләр дәвам итә. Гореф-гадәт , йолалар безгә рухи азык бирә,туган җиребезне сагынып кайтуга җирлек тудыра, матурлыкны күрә белергә, аны тоярга өйрәтә.
А.Б.Авыллардагы үзгәрешләр кискен барса да, яшәеш дәвам итә. Бүгенге көндә авылларны шәхси эшмәкәрләр, фермер хуҗалыклары эшле итеп тота.
Укучылар сөйләве.
А.Б. Әйе, берничә ел элек авыллар , чыннан да бомба төшкән кебек , катастрофа хәлендә иде. Автор үзенең хатларында атом төш бомбасы шартлаганда, аның нурланышы бөтен нәрсәне көйдереп узуын әйтеп уза.Илдәге катастрофаны шушы бомба белән чагыштыра.
А.Б.Ә бит чыннан да Япониянең иң тыныч шәһәрләренә Херосима һәм Нагасакига Германия атом бомбасы ташлый. Меңләгән кешеләр вафат була, шәһәр тулысынча җимерелә, никадәр нурланыш мәңгелек булып кала. Хәзер күрсәтеләчәк спектаклҗнең сюжеты нәкъ менә шул турыда.
Спектакль
А.Б.Автор:”Авыл йөрәктәге мәңгелек давыл!киләчәккә җир йөзендә сакланып калачагына ышаныч тумый торып, бу утлы давыл беркайчан да тынмаячак” ди.
Без инде “Авылдан хатлар”әсәрен дәвам итеп олуг язучыбызга сүзне бирик. Фоат ага бүгенге көндәге авыл тормышына сезнең фикерләр.






атарга тырыштылар.




17.11 көнне "Мәктәптән тыш эшләр үзәгендә" икенче ел рәттән робототехника буенча республикакүләм "РобоКвест" ярышы узды. Квестта Татарстанның 9 районыннан килгән 15 командадан 60 укучы көч сынады. Киеренке ярыш нәтиҗәсендә безнең мәктәп командасы сертификат, ә «Сумо» сынавында Фазлыев Наиль 3 нче урын алды. Котлыйбыз!Игътибар!!!



10-11 ноябрьдә йөзү буенча спорт мәктәбенең җыелма командасы Чистай шәһәрендә йөзү буенча "Лидер Закамья" республика ярышларында катнашты. Багауова Динә 100 метр дистанциядә көмеш медаль яулады. Котлыйбыз!..



“SFORZANDO” Республика форумы кысаларында үткәрелүче күпжанрлы “Сәнгать осталары" конкурсында Гран-при алган "Тукай бизәкләре" һәм "АсСа" бию төркемнәрен котлыйбыз! Молодцы!.




11 ноябрь көнне Беренчеләр хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе Советы рәисен сайлаулары узды. 40% тавыш җыеп әлеге вазыйфага укучыбыз Сөмбел Ибраһимова билгеләнде. Горурланабыз һәм чын күңелдән котлыйбыз!



# Укучыларыбыз иҗаты

## 10 "а"сыйныфы укучылары яза...

## Әнием, мин сине ЯРАТАМ...

Минем гомеремдә иң яраткан кеше- ул Әни. Әниемнең исеме - Лилия, аның чәчләре кара төстә, ә көрән күзләре гел янып тора. Әтием белән күрешкәнче, әнием Мәскәү шәһәрендә торган. Метрәй дигән авылга кунакка кайткач, әти белән танышкан. Беренче булып әни кафеда эшләгән, хәзер инде педагог булып эшли. Көн саен әнием "Тор улым, яңа көн җитте " - диеп үбеп уята. Эшкә киткәнче тәмле итеп ашарга пешерә. Мин берәр эшне начар эшләсәм, әнигә ул барыбер бик ошый. Минем әнием һәр кешегә булышырга тырыша. Һәм кеше өчен әни- иң кадерле кеше! Мин әниемне иң әйбәте, иң матуры дип саныйм! Әни, мин сине яратам! **Гыйльметдинов Ислам**

Кадерле әнием, без бер өйдә яшибез. Без бер-беребезне гел күрәбез. Мин сине көн саен, яхшы тәртибем белән сөендерергә тырышам һәм сиңа һәрвакыт булышам. Син минем һәр әйткән сүземне тыңлыйсың. Син- дөньядагы иң яхшы укытучы. Син мине гел уңай булырга өйрәтәсең. Ләкин мин сиңа иң мөһим сүзләрне әйтмим. Бүген мин аны әйтәм. Яраткан әнием, мин сине нык яратам.. Рәхмәт сиңа мине бу дөньяга китергән очен. Барысы өчен дә рәхмәт! **Габидуллина Рүзилә**

Бүген, бу бәйрәм көнендә, мин җирдәге иң яхшы кешегә - әниемә ихлас рәхмәтемне җиткерәсем килә! Кадерлем һәм дөньяда иң яраткан әнием! Әни, мин сине бик яратам һәм синең дә мине ятратканыңны беләм. Бу мәхәббәтең, тормышымны яктырткан яктылыгын өчен мин сиңа бик рәхмәтле. Тагын, әни, мин сиңа үрнәгең белән мине яхшылык, сабырлык, зирәклек, ярдәм, нәфислек һәм матурлыкка өйрәтүең өчен рәхмәтле. Кыскасы, кеше бу тормышка бары тик иң яхшы әйбер генә китерә ала. Моннан да яктырак кешене мин үз гомеремдә бер тапкыр да очратмадым һәм, минем уйлавымча, андыйлар башка юк. **Төхбәгалиева Камилә**

Минем әниемнен исеме Гөлшат Загитовна. Ул минем иң якын кешем! Мин аның коңгырт кара күзләрен, җылы, йомшак кулларын һәм кыңгырау чыңына охшаган көлүен яратам. Минем әнием матурлык, эшчәнлек, сабырлык һәм тырышлык белән аерыла. Әнием мине һәм минем энемне туганнан бирле яратып, назлап кына үстерде, һәрвакыт терәк булды. Мин аңа бу матур дөньяга китергән, һәрвакытта минем өчен борчылып торган өчен гомерем буе бурычлы булачакмын. Мин бары борчылу хисләрен дә әниемә сөйлим. Ул миңа һәрвакыт ярдәм итә. Әни белән мин үземне куркынычсыз хис итәм. Мин әниемне бик яратам. **Нуреева Алия**

Иң кадерле кеше ул - Әни. Минем әнием - Ләйсән. Икенче елга аның юбилее булачак. Ул медсестра булып әллә ничә еллар эшләде. Күп кешеләргә ярдәм итте. Бәләкәй чактан ук әни безне калдырмады. Үзе генә 3 баланы карады. Бөтен авырлыкларны җиңеп чыга алды. Әнинең кәефе юк булса да, ул аны күрсәтмәскә тырыша. Авыр хәлләр булганда әни белән киңәшәм. Аның алтын куллары. Күбрәк булышырга, йорт эшләрендә кул арасына керергә кирәк. Аздан да күңелләре булып куя бит аларның. Әни безне бик ярата, тигез күрә. Ул безгә тәмле-тәмле ризыклар пешерә, кичен назлап йоклата, ә иртән "улым" диеп сөеп уята. Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Көннәрем син булганга аяз, төннәрем ай-йолдызлы якты. Салкыннарда күңел җылыңны биреп җылытасың, безнең өчен ял димисең, һәрвакыт хезмәт итәсең. Кешенең беренче әткән сүзе әни булган. Әниләрне хөрмәт итәргә кирәк. Әнием, мин сине яратам**.** **Суфиев Данис**

Әнием, син миңа бик нык кадерле! Син миңа авыр вакытларда гел булышырга торасың! Мин синең белән горурланам, югары бәялим! Синең елмаю минем рухымны күтәрә, синең күзләрең бик матур, син пешергән ризыкларың бик нык тәмле! Син минем мәхәббәтем!!!Әнием, мин сине яратам❤ **Сәлахов Камил**

Кадерле әнием, син бу дөньяда минем өчен иң кадерле кеше! Минем сиңа бик зур рәхмәт әйтәсем килә: бу дөньяга мине китергән, үзеңнең йөрәгеңдә миңа җылы урын тапканың өчен. Авыр чакларда сине игътибар белән тыңлап, үзенең ярдәм кулын сузарга һәрвакыт әзер булучы кем? Әлбәттә, әнием! Мин сине беркайчан да кызартмаска, яхшы хәбәрләр белән генә сөендерергә тырышырмын. Мин сине бик яратам! **Гыйльметянова Эльвина**

Минем әнием- минем өчен иң кадерле кеше. Әниемә һәркөнне мәхәббәт сүзләрен әйтмәсәм дә, мин аны бик яратам. Күпләр әниләре белән үткәргән мизгелләрне кадерләмиләр, бик сирәк килеп, соңыннан үкенәләр. Мин аның белән яңгырлы кичләрен җылы чәй өстәле янында сөйләшергә яратам. Аның күз яшьләрен күргәч, йөрәгем мине борчый башлый. Минем әнием ап-ак яз чәчәкләренә охшаган. Ул бик ягымлы һәм матур. Кайвакыт миңа ул яңа март җиле исен хәтерләтә. Шуңа күрә әни турында балачактан ук кайгыртырга, яратырга һәм хөрмәт итәргә, кадерләргә һәм ләззәтләнергә кирәк. Аның күзләре минем тормыш юлын яктырта. Аның шаян көлүе мине бәхет белән тутыра. Әнием, мин сине бик яратам. Бик зур рәхмәт сиңа! **Демидова Диләрә**

Минем өчен иң кадерле кеше - әнием. Минем әнием дус, игелекле, йомшак, назлы, шат. Ул авыр вакытта булыша һәм кирәкле киңәшләр бирә белә. Минем әниемнең бик матур бөдрә чәчләре бар, алтын чәчле кырны хәтерләтә. Әниемнең күзләре зәңгәр күк кебек. Алар һәрвакыт ачык һәм яхшы теләк тараталар. Аның иреннәре пешкән чия кебек ачык кызыл. Аның йөзе һәрвакыт йомшак елмаю белән яктыртыла, бу сезнең рухыгызны күтәрә һәм арыганлыкны җиңеләйтә. Әни тыныч кына, йомшак тавыш белән сөйләшә. Аның белән тыңлау һәм сөйләшү кызык һәм күңелле. Минем әни бик сабыр һәм сыгылмалы. Барысы да аны хөрмәт итәләр һәм яраталар. Мин әнием белән бик горурланам. **ГизетдиноваЗәйнәп**

Кем сон ул Әни? Әни кеше ул һәркемнең ин якын, иң яраткан кешесе бит, ялгыш кына әйтмиләр бит җәннәт әниләр астында. Минем әни Айгөл,ул Мөслимнең <Маяк> социаль үзәгендә специалист булып эшли. Менә син иртә белән йокыдан уяндың да күзләреңне ачтың. Бүлмә кояш нуры белән балкып тора. Өйдә тәмле аш исе аңкый. Сиңа бик рәхәт. Син шул вакытта үзең дә сизмәстән, "әни" дип эндәшәсең. Нигә? Чөнки хәзер бу иртәнге сәгатьтә синең йөрәгеңдә шатлык тыпырчына һәм ул менә хәзер "әни" дигән сүз булып синең күкрәгеңнән очып чыкты да ананың күңеленә барып кунды. Ананың йөзе елмайды, күзләре энҗе кебек ялтырап китте. Нигә? Чөнки "әни" дигән сүз белән аңа иртәнге сәгать тагы да матуррак булып китте. Аның күңеле татлы хисләр белән тулды. Әни..Нинди олы сүз бу! Кеше үз гомерендә шул сүзне ничәмә-ничә кабат әйтә икән? Әйткән саен, сүз яңадан-яңа мәгънә алып килә. Ана шул бер сүздән синең шатлыгыңны да, кайгыңны да, уйларыңны да белә. Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием – кадерлеләрдән дә иң

кадерлесе. Әнием, мин сине яратам!❤ **Гамиров Амир**

Минем әнием миңа бик кадерле. Ул- яхшы, сабыр кешеләрнең берсе. Ул миңа гел матур сүзләр әйтә. Әниемнең йомшак, жылы куллары, ягымлы тавышы миңа шатлык китерә. Мәктәптән өйгә кайткач, ул мине елмаеп каршы ала, һәм миңа шунда ук жылырак һәм яктырак була. Әниемне кулсыз күз алдына да китереп булмый. Әнинең куллары сихри, алар синең өчен барысын да эшлиләр: ризык әзерлиләр, киемнәр тегәләр, киенергә ярдәм итәләр һәм башкалар. Әниемнең куллары иң көчлесе, чөнки әни барысын да күтәрергә булышачак, хәтта бик авырны да. Минем әнием бик жаваплы. Аның бик житди эше бар, ул өйгә бик арыган булып кайта. Әни булганда , өебез нурлы, аның күзләреннән бөркелгән нур һәрберебезгә жылылык бирә. Әнием янәшәсендә булганда гына мин үземне бәхетле хис итәм. Әнием кешеләргә карата ягымлы, ярдәмчел булырга өйрәтә, мине миһербанлы, акыллы булып үсүемне тели. Әниемнең биргән киңәшләре жанга дәва бирә, киләчәккә ышаныч уята, яшәү дәрте бирә. Әнием, мин сине бик яратам! Син- минем өчен иң мөһим кешеләрнең берсе. **Шәгалиева Ләйсән**

Әнием- минем өчен иң кадерле кеше. Мин аны бик яратам. Аның һәрвакыт янымда булган өчен яратам. Мин бик әниемне кадерлим. Әниемнән дә якын кеше юк. Минем әниемнең исеме Алия Флеровна. Ул чибәр. Әниемнең елмаюын һәм зур күзләрен яратам, әнием бик игелекле, һәркем аны хөрмәт итә һәм ярата. Ул миңа авыр вакытларда ничек булышырга белә.Әни туганнан бирле апаем белән минем турында кайгыра, безгә үзенең назын һәм мәхәббәтен бирә. Мин әниемә кылган һәр эше өчен бик рәхмәтле. Аңа һәрвакыт берәр нәрсәдә булышырга тырышам. Минем әни бик тәмле пешерә, һәм мин аңа булышырга яратам. Әни белән саф һава суларга яратам. Мин әниемнең беркайчан да үпкәләмәвен телим. Минем әниемә бәхет, сәламәтлек һәм теләгән барын да телим. Аның бөтен хыяллары тормышка ашсын. Без бит, балалар гына түгел, мәхәббәт, игътибар һәм кайгырту кирәк - әни дә аларга мохтаж. Кадерле әни, мин сине бик яратам! Мин сезне көн саен укуларым, яхшы тәртибем белән сөендерергә тырышырмын һәм сезгә һәрвакыт булышырмын. Әни, булуың өчен рәхмәт! **Ситдикова Адиля**

Минем әнием- иң яхшы кеше. Минем өчен әнидән дә кадерлерәк һәм якынрак кеше юк. Ул- мине һәрчак аңлаган һәм мине нинди булсам да кабул иткән бердәнбер кеше. Әнием мине ялгышкан очракларда ачуланмый, ярдәм кулы суза. Киресенчә, ул миңа һәрвакыт ярдәм сүзләре әйтә һәм кулларны төшермәскә чакыра. Ул һәрвакыт минем турында кайгырта һәм авыр вакытларда ярдәм итә. Әниемә рәхмәтемне белдерәсем килә. Әни, минем өчен эшләгән бар эшең өчен рәхмәт. Көн саен минем турында кайгыртуың өчен рәхмәт. Хәтта күрсәтмәсәм дә, мин моны бик кадерлим. Әнием, мин сине кайвакыт рәнжеткән өчен гафу ит. Мин беләм, син мине бар әйбер өчен дә гафу итәсең һәм моның өчен дә мин бик рәхмәтле. Әнием, мин сине яратам. **Шәймиева Рушания**

Минем исемем Динә була.Ин кадерле, ин якын кеше ул миңа- әни. Хәзер мин сезне үземнең әни белән таныштырып китәсе килә иде. Аның исеме Миләүшә була,туганнары аны миләш диеп йөртәләр.Әнием минем 15 ел буена татар теле укытучысы булып эшләде. Башта Табын мәктәбендә,ә аннары Мөслимг күчкәч, гимназия мәктәбендә эшли башлады.Минем әнием ни генә эшли белми ул. Бөтен һөнәрләр дә әз аңа. Минем әниемнең медовигы ин тәмле нәрсәләрнең берсе ул. Анын тәмле, татлы тәмен бер нәрсә дә уза алмый. Ул тәмне мин беркайчан да онытмаячакмын. Әнием- ул минем горурлыгым. Ул- минем ин яраткан кешем. Мин һәрвакыт әниемә бөтен борчуларымны сөйли алам, ул миңа һәрвакыт ярдәм итәчәк.Мин бик рәхмәтле әниемә, чөнки ул миңа тиешле тәрбия бирде. Ул миңа кызның нинди булырга тиеш икәнен күрсәтте. Яратам сине, Әнием!! Мин сине берәр нәрсә өчен түгел, ә болай гына яратам! **Амирова Динә**

Минем әниемнең исеме - Гөлназ, минем әни мәктәптә укытучы булып эшли, биология укытучысы, һәм минем өчен әни самый әйбәт, чибәр, матур кеше. Аның кузләре яшел, чәче көрән төстә. Мин әниемне бик нык яратам, чөнки минем өчен аннан да кадерлерәк кеше юк, һәм ул нык тәмле ашарга пешерә, дөньяда аның ашамлыгыннан тәмлерәк юктыр. Мин нык яратам әниемне, ул мине гел поддерживать итә, берәр жирем авырта икән, әни гел булыша. Мин әниемне нык яратам**.** **Деникаев Айнур**

Минем өчен әни тормышымда иң мөһим кеше. Кирәк вакытта ул киңәшче, дус булырга мөмкин. Әни һәрвакыт ярдәмгә килә. Мин аны яратам, чөнки ул минем өчен һәм минем бәхетем өчен барысын да эшләде. Әни без туганда күргән беренче кеше. "Әни" сүзен беренче әйтәләр. Безнең әни гаиләдә кояш нуры.Ул һәрвакыт һәркайсы сорауларны хәл итәчәк һәм аларда чишелешләр табачак. Әнием өйдә барысын да эшли, мин моңа һәрвакыт гаҗәпләнәм.Өй эше һәм башка проблемалар белән безгә булыша.Кухняда ул сихерче, аның һәркайсы ризыгы барысыннан да яхшырак була. Ул безнең өйдә уңайлык тудыручы гаҗәеп хатын.Мин аны бик яратам, чөнки ул мине тудырды, тәрбияләде, миңа ярдәм итүче, яхшы киңәшләр бирүче. Мин аны бик нык яратам! **Солтанова Азалия**

Безнең һәрберебез өчен тормыштагы иң кадерле кеше, әлбәттә, әниебез. Әни безгә тормыш бирде, безнең әниебез һәрвакыт назлы һәм игътибарлы. Ә ана йөрәгендә күпме мәхәббәт һәм газап була алуын, күпме тәҗрибә кичерә алуын беркем дә белми. Чөнки бала авырып китсә яки аның белән авария килеп чыкса, аның әнисе аны дәвалый һәм аны кызгана. Балалар олы булгач, ана алар белән мөстәкыйль тормыш тәҗрибәләре белән уртаклаша. Әни булуына карамастан, безне гомере буе озата ул безнең яндамы яки бездән меңләгән чакрым ераклыктамы. Кайда гына булсак та, әни мәхәббәте, ана догалары һәм борчылулары безне бәхетсезлекләрдән һәм тормыш авырлыкларыннан саклый. Ләкин әниебезнең безне никадәр яратуын белеп, без аңа бик еш игътибар итмибез, еш кына аларга салкын яки хәтта битараф карыйбыз. Ләкин, моңа карамастан, әни генә безне һәрвакыт яратыр, безне һәр җирдә һәм теләсә нинди шартларда яратыр. Ана өчен аның баласы һәрвакыт дөньяда иң яхшысы. **Латипов Нурислам**

Ананың йөрәге генә үз балаларына мәхәббәтне теләсә нинди шартларда тоя. Ана яңа туган баласын беренче тапкыр кочагында тоткач, аның йөрәге зур шатлык белән тула, ул аны үз баласы белән бүлешергә әзер. Минем әнием - бөтен җанын бирүче һәм мине тәрбияләү өчен кайгыртучан кеше, моның өчен мин аңа бик рәхмәтле. Әниемә карасам, минем күз алдымда назлы һәм кайгыртучан балачак турында җылы хатирәләр пәйда була, һәм мин аңлый алмыйм, шулкадәр кечкенә ана йөрәгенә шулкадәр мәхәббәт ничек туры килә? Әни минем өчен бик якын дус кына түгел, минем фикеремә һәм кызыксынуларыма хөрмәт һәм аңлау белән караучы кеше. Ни кызганыч, кеше бу ана йогынтысын һәрвакыт бәяли алмый.. Без әниебезне рәнҗетмәскә тиеш, чөнки әни - безнең тормышта иң кадерле һәм матур кеше. Әни - тормышның иң яхшы бүләге. Кызганычка каршы, бүген күпләр бу бәхеттән мәхрүм, чөнки алар ана йөрәге мәхәббәтен кадерләмиләр. Әйдәгез, әниләребезгә хөрмәт һәм наз белән карыйк! **Сабиров Айрат**

Тормышымдагы иң кадерле кеше- ул минем әнием. Минем әниемә хәзерге вакытта 41 яшь, ләкин ул һаман да 18 яшьлек кыз шикелле генә. Ул бик актив, матур, һәм "әйдә" генә дип тора торган кеше. Күпме мин үземне хәтерлим, минем әнием мина гел киңәшче һәм ярдәмче булды. Ул һәрчак миңа яхшылык гына теләп, мине бик яратып үстерде. Минем әнием һәрвакыт минем янымда, авыр минутларда да ул мина ярдәм итә. Әниемә генә мин бар серләреме курыкмыйча сөйли алам, һәркайсы борчулыны ул бер секундта ук бетерә. Әниемнең йөзенә карагач та, минем бөтен кайгым юкка чыга. Ул мине өчен дус та, шул вакытта әни дә. Тагын бер бик мөһим әйбер, безнең әни белән мөнәсәбәтләрдә ул без бер-беребезгә ярату сүзләрен әйтергә курыкмау. Без һәрчак бер- беребезгә "мин сине яратам дибез", минемчә, ул бик мөһим роль уйный сыман. Бу иншаның нәтиҗәсе булып, минем тагын бер тапкыр кабытлыйсы килә, әнием мин сине бик нык яратам, син- минем гомеремдә иң мөһим кеше. **Мәгалимова Аделя**

«Тукай ялкыны”, ноябрь, 2023 нче ел, Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылары газетасы Баш мөхәррир: Гайнетдинова Г.Ф.
Корреспондентлар Нуреева Алия, Җаббарова Диана
Дизайнер Әсәдуллина Айзилә. Компьютерда җыючы: Галеева Камилә, Миргалимова Эльвина .Гамәлгә куючы: Г.Тукай ис.Мөслим урта мәктәбе укучылар иҗат үзәге Адрес: Мөслим, Тукай 21 Электрон адрес: s2.mus@mail.tatar.ru 100 экземпляр